**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советы утырышы**

# КАРАРЫ

“20” февраль 2026 ел № 13

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 108 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмә”гә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставына таянып, Комыргуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 108 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмә”гә (26.05.2025 № 123 үзгәреше белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1.1.7.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә**:

«7.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган, әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.»;

**1.2. 7.2. пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7.2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар, һәм башка затларның аларның керемнәренә чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында мәгълүматларны Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм рәвештә тапшырырга тиеш.»;

**1.3. 7.4. пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7.4. Әлеге бүлек нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматлар, әгәр федераль законнар белән алар дәүләт һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматларга кертелмәсә, конфиденциаль характердагы мәгълүмат булып тора»;

**1.4. 7.5. пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7.5. Әлеге бүлек нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны, муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ

булмаган балаларының түләүгә сәләтлелеген билгеләү, дини яисә башка иҗтимагый берләшмәләр, бүтән оешмалар, шулай ук физик затлар фондларына турыдан-туры яисә читләтеп иганәләр (кертемнәр) җыю өчен файдалану рөхсәт ителми.»;

**1.5. 7.6. пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7.6. Әлеге бүлек нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны ачуда, яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда әлеге мәгълүматларны файдалануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.»;

**1.6. 7.7. пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7.7. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан мәгълүматлар тапшырылмаса һәм «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның аларның керемнәренә чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында мәгълүматлар, әгәр мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри булса, яки беләторып тулы булмаган мәгълүматлар тапшырылса, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәт хезмәткәрен эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

**1.7. 7.10. пунктын үз көчен югалткан дип танырга;**

**1.8. 9.3. пунктның 10 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы: Ш.М.Шарипов